| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.01.2025 с.Старое Дрожжаное № 10

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы (31.10.2018 № 965, 29.12.2018 № 1262, 06.05.2019 № 380, 11.07.2019 № 565, 28.08.2019 № 714, 02.11.2019 № 1008, 30.12.2019 № 1278, 16.04.2020 № 294, 21.05.2020 № 413, 01.09.2020 № 772, 23.10.2020 № 954, 26.07.2021 № 645, 06.09.2021 № 821, 29.10.2021 № 1021, 30.10.2021 № 1030, 15.06.2022 № 566, 22.09.2022 № 1027, 24.06.2024 № 454, 25.09.2024 № 830 ТР МК карары ред.) карарының гамәлдә булуын түбәндәге хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартларына таратырга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мәгариф оешмаларының гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләре, җитәкчеләре, белгечләре һәм гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз органы белән килештереп, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы

муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартларын билгеле торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 июнендәге 286 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов